**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 сентябрь № 635

г. Казань

Территорияләрендә спорт ярышларында катнашучылар, Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү чараларында катнашучы башка затлар һәм тамашачылар өчен күмәк урнаштыру урыннары булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеген раслау турында

«Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын, 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 7 июнь, ФЗ-108 нче Федераль законның 36 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Территорияләрендә спорт ярышларында катнашучылар, Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү чараларында катнашучы башка затлар һәм тамашачылар өчен күмәк урнаштыру урыннары булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеген (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан, спорт ярышларында катнашучылар, чараларда катнашучы башка затлар һәм тамашачылар өчен кунакханә хезмәтләре, вакытлыча урнаштыру һәм (яки) вакытлыча яшәп торуны тәэмин итү хезмәтләре күрсәтүче күмәк урнаштыру урыннарын классификацияләү мониторингын гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр территорияләрендә урнашкан, спорт ярышларында катнашучылар, Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы

FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү чараларында катнашучы башка затлар һәм тамашачылар өчен кунакханә хезмәтләре, вакытлыча урнаштыру һәм (яки) вакытлыча яшәп торуны тәэмин итү хезмәтләре күрсәтүче күмәк урнаштыру урыннарын классификацияләүне тәэмин итүгә, шулай ук классификацияләнергә тиешле һәм категория бирү турында шәһадәтнамә алган урнаштыру урыннарының реестрын актуальләштерүгә юнәлдерелгән чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 10 сентябрь, 635 нче
карары белән расланды

Территорияләрендә спорт ярышларында катнашучылар, Россия Федерациясендә 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын һәм 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү чараларында катнашучы башка затлар һәм тамашачылар өчен күмәк урнаштыру урыннары булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемлеге

1. Әгерҗе муниципаль районы
2. Азнакай муниципаль районы
3. Аксубай муниципаль районы
4. Актаныш муниципаль районы
5. Алексеевск муниципаль районы
6. Әлки муниципаль районы
7. Әлмәт муниципаль районы
8. Апас муниципаль районы
9. Арча муниципаль районы
10. Әтнә муниципаль районы
11. Баулы муниципаль районы
12. Балтач муниципаль районы
13. Бөгелмә муниципаль районы
14. Буа муниципаль районы
15. Югары Ослан муниципаль районы
16. Биектау муниципаль районы
17. Чүпрәле муниципаль районы
18. Алабуга муниципаль районы
19. Зәй муниципаль районы
20. Зеленодольск муниципаль районы
21. Кайбыч муниципаль районы
22. Кама Тамагы муниципаль районы
23. Кукмара муниципаль районы
24. Лаеш муниципаль районы
25. Лениногорск муниципаль районы
26. Мамадыш муниципаль районы
27. Менделеевск муниципаль районы
28. Минзәлә муниципаль районы
29. Мөслим муниципаль районы
30. Түбән Кама муниципаль районы
31. Яңа Чишмә муниципаль районы
32. Нурлат муниципаль районы
33. Питрәч муниципаль районы

34. Балык Бистәсе муниципаль районы
35. Саба муниципаль районы
36. Сарман муниципаль районы
37. Спас муниципаль районы
38. Тәтеш муниципаль районы
39. Тукай муниципаль районы
40. Теләче муниципаль районы
41. Чирмешән муниципаль районы
42. Чистай муниципаль районы
43. Ютазы муниципаль районы
44. Казан шәһәре
45. Чаллы шәһәре